**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге составына керүче Вольнистан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

17.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; - су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Вольнистан авылында кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны - 241 кеше. Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 229 катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 120 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 120 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Янтуган авыл җирлегенең Вольнистан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; - су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Вольнистан авылында кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу, эшләр һәм договор буенча хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Вольнистан авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Янтуган авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ Р.А.Җамалтдинов

Янтуган авыл җирлеге
башлыгы _________________ Р.А.Җамалтдинов